ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында»
Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына
үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Иҗтимагый палата» сүзләрен «1. Иҗтимагый палата» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Иҗтимагый палата җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплый һәм аның эшчәнлеген матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүдә ярдәм күрсәтә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 97-ТРЗ